# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль вазыйфаларны, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (биләгән) затларны пенсия белән тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 4 өлешенә (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2009, 9 декабрь), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"4. Дәүләт хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия, 15 ел дәүләт хезмәте стажы булганда, дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата вазыйфаи тулы кеременең 50 проценты күләмендә билгеләнә, моннан картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлеше йә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе алып ташлана. Дәүләт хезмәте стажының 15 елдан арткан һәр тулы елы өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсия айлык акчалата вазыйфаи тулы керемнең 3 процентына арта бара. Бу чакта тиешле еллар эшләгән өчен пенсиянең һәм картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең йә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең гомуми суммасы дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата вазыйфаи тулы кеременең 80 процентыннан артык була алмый.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән тәртиптә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә гаиләнең хезмәткә сәләтсез

әгъзаларына һәм 80 яшькә җитүгә яисә I төркем инвалидлыкка ия булуга бәйле рәвештә әлеге билгеләп куелган база күләмен арттыруга туры килә торган картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләме (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең билгеләп куелган база күләме) суммалары, "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә, күрсәтелгән Федераль законның 17 статьясындагы 6 пункты һәм $17^1$ статьясына таянып, индексациягә (өстәмә арттырылуга) һәм яңадан исәпләүгә (корректировкалауга) бәйле аның арту суммаларын кертеп, тулысынча кимендә 12 ай эшләү һәм (яисә) башка эшчәнлек чорына тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнгәннән соң иминләштерелгән зат өчен Россия Федерациясе Пенсия фондына кергән иминият кертемнәренең гомуми суммасы исәбеннән, шулай ук "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә пенсия хокукларының валоризациясенә бәйле рәвештә түләнергә тиешле суммалар исәбеннән формалаштырылган хисапланган пенсия капиталыннан чыгып исәпләп чыгарылган картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлеше күләме исәпкә алынмый.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнгән картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләменнән кимрәк була алмый.".

**2 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); № 12 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"2. Пенсиягә өстәмә өстәмәнең һәм картлык буенча хезмәт пенсиясенең йә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең гомуми суммасы: дәүләт вазыйфасын бер елдан алып өч елга кадәр биләгәндә – тиешле вазыйфа буенча хисапланган айлык акчалата вазыйфаи тулы керемнең 55 проценты, өч елдан артык биләгәндә – 75 проценты күләмендә булырлык итеп билгеләнә.

Пенсиягә өстәмә күләмен әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән тәртиптә билгеләгәндә гаиләнең хезмәткә сәләтсез әгъзаларына һәм 80 яшькә җитүгә яисә I төркем инвалидлыкка ия булуга бәйле билгеләп куелган әлеге база күләмен арттыруга туры килә торган картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләме (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең билгеләнгән база күләме) суммалары, шулай ук "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә пенсия хокукларының валоризациясенә бәйле рәвештә түләнергә тиешле суммалар исәпкә алынмый.

Пенсиягә өстәмә күләме "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнгән

картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләменнән ким була алмый.".

**3 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында" 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1, №7 (I өлеш), № 12 (I өлеш), № 12 (VI өлеш); 2009, № 2; Ватаным Татарстан, 2009, 1 август), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"4. Муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия, 15 ел муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тулы кеременең 50 проценты күләмендә билгеләнә, картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлеше йә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе алып ташлана. Муниципаль хезмәт стажының 15 елдан арткан һәр тулы елы өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсия айлык акчалата вазыйфаи тулы керемнең 3 процентына арта бара. Бу чакта тиешле еллар эшләгән өчен картлык буенча пенсиянең иминият өлешенең йә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең гомуми суммасы муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата вазыйфаи тулы кеременең 80 процентыннан артык була алмый.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән тәртиптә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә гаиләнең хезмәткә сәләтсез әгъзаларына һәм 80 яшькә җитүгә яисә I төркем инвалидлыкка ия булуга бәйле рәвештә әлеге билгеләп куелган база күләмен арттыруга туры килә торган картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләме (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең билгеләп куелган база күләме) суммалары, "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә, күрсәтелгән Федераль законның 17 статьясындагы 6 пункты һәм $17^1$ статьясына таянып, индексациягә (өстәмә арттырылуга) һәм яңадан исәпләүгә (корректировкалауга) бәйле аның арту суммаларын кертеп, тулысынча кимендә 12 ай эшләү һәм (яисә) башка эшчәнлек чорына тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнгәннән соң иминләштерелгән зат өчен Россия Федерациясе Пенсия фондына кергән иминият кертемнәренең гомуми суммасы исәбеннән, шулай ук "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә пенсия хокукларының валоризациясенә бәйле рәвештә түләнергә тиешле суммалар исәбеннән формалаштырылган хисапланган пенсия капиталыннан чыгып исәпләп чыгарылган картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлеше күләме исәпкә алынмый.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнгән картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләменнән кимрәк була алмый.".

**4 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка пенсиягә өстәмә пенсиягә өстәмә билгеләү өчен 15 ел стажы булганда тиешле муниципаль вазыйфа буенча айлык акчалата вазыйфаи түләүнең 50 проценты күләмендә билгеләнә, моннан картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлеше яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясе алып ташлана. 15 елдан арткан стажның һәр тулы елы өчен пенсиягә өстәмә айлык акчалата вазыйфаи түләүнең 3 процентына арта бара. Бу чакта пенсиягә өстәмәнең һәм картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең йә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең гомуми суммасы муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның айлык акчалата түләвенең 80 процентыннан артык була алмый.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән тәртиптә пенсиягә өстәмә күләмен билгеләгәндә гаиләнең хезмәткә сәләтсез әгъзаларына һәм 80 яшькә җитүгә яисә I төркем инвалидлыкка ия булуга бәйле рәвештә билгеләп куелган әлеге база күләмен (инвалидлык буенча хезмәт пенсиясенең билгеләп куелган база күләмен) арттыруга туры килә торган картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләме суммалары, шулай ук "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә пенсия хокукларының валоризациясенә бәйле рәвештә түләнергә тиешле суммалар исәпкә алынмый.";

2) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Пенсиягә өстәмә күләме "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнгән картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең билгеләп куелган база күләменнән кимрәк була алмый.".

**5 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2010 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

2. Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны, Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затларга Татарстан Республикасы законнары нигезендә 2010 елның 1 гыйнварына кадәр тиешле еллар эшләгән өчен билгеләнгән пенсияләр (пенсиягә өстәмәләр) "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 4 өлеше (әлеге Закон редакциясендә), "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 2 өлеше (әлеге Закон редакциясендә), "Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында" 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 4 өлеше (әлеге Закон редакциясендә), "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 2 һәм 4 өлешләре (әлеге Закон редакциясендә) нигезендә аларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсия (пенсиягә өстәмәләр) билгеләү юлы белән яңадан каралырга тиеш. Бу очракта 2010 елның 1 гыйнварына кадәр тиешле еллар эшләгән өчен пенсия (пенсиягә өстәмәләр) күләме күрсәтелгән Татарстан Республикасы законнарында (әлеге Закон редакциясендә) каралган тиешле еллар эшләгән өчен пенсия (пенсиягә өстәмәләр) күләменнән артса – гражданның тиешле еллар эшләгән өчен югарырак күләмдәге пенсиягә (пенсиягә өстәмәләргә) хокукы саклана.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2010 елның 13 гыйнвары
№ 5-ТРЗ